


# Дәрес-презентация

# Иярчен җөмләләрнең төзелеш ягыннан төрләре

***Синтетик иярчен җөмлә***

# *Синтетик сүзе нәрсә анлата?*



**Синтетик** ( “синтез” сүзеннән) – ***анализ юлы белән табылган мәгълүматларны бер бөтенгә берләштерүдән, гомумиләштерүдән гыйбарәт булган тикшерену методы.***

# ***Җөмлә*** (1)

1. *Абый җырлый башла****гач,*** караңгы юл киңәеп, яктырып киткәндәй булды.

( ... – гач ), [ ]

# ***Җөмләләр*** (2)

2. Ул*, дәресләр иртә бетү****гә карамас******-тан****,* өйгә кайтырга ашыкмады.
   [... , (...-***гә карамастан***), ...]
3. *Иртәгә әнисе авылдан кил****ү сәбәпле,*** Нәсимә өйне җыештырып куйды.

   ( ... - ***ү сәбәпле***), [ ]

# ***Җөмлә*** (3)

*4. Суы салкын* чишмәләр күп бу тирәдә.

( ) [ ]

# Таблица

| *Мисаллар* | *Схема һәм бәйләүче чаралар* |
| --- | --- |
| 1. *Абый җырлый башла**гач**,* караңгы юл киңәеп, яктырып киткәндәй булды. | 1. (... ***- гач***), [ ]<br><br>**Кушымчалар** |
| 2. Ул, *дәресләр иртә бетү**гә карамастан,*** өйгә кайтырга ашыкмады.<br>3. *Иртәгә әнисе авылдан килү **сәбәпле,*** Нәсимә өйне җыештырып куйды. | 2.[...,(...*-**гә карамастан***),... ]<br><br>3. (... – ***ү сәбәпле***), [ ]<br>**Кушымчалар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр** |
| 4. *Суы салкын* чишмәләр күп бу тирәдә. | 4. ( ) [ ]<br>**Ике җөмлә арасында пауза юк – янәшә тору чарасы** |

# Синтетик иярчен җөмләләрнең төп билгеләре

1. Бәйләүче чаралар – кушымчалар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, янәшә тору.
2. Бәйләүче чаралар иярчен җөмләнең хәбәре составында тора.
3. Синтетик иярчен җөмлә баш җөмләнең я башында, я уртасында гына килә ала, ахырдан килеп, кушма җөмләне тәмамлый алмый.

# *Нәтиҗә*



**Баш җөмләгә үзенең хәбәре составындагы чаралар ярдәмендә ияргән, шунлыктан аңа керешеп киткән җөмлә *синтетик иярчен җөмлә* дип йөртелә**

# Өстәмә

**Синтетик иярчен җөмләләр татар теленә һәм гомумән төрки телләргә хас, рус телендә алар юк**

